КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1050

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 17 апрель, 310 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карап тикшерү һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карап тикшерү һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 17 апрель, 310 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 25 май, 394 нче; 2020 ел, 17 апрель, 297 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проект-

ларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карап тикшерү һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төбәк әһәмиятендәге объектларны урнаштыруны планлаштыруга бәйле рәвештә, махсус шартлары булган территорияләрдән файдалану зоналарын билгеләгәндә, Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый алган төбәк әһәмиятендәге объектларны урнаштырганда, Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен саклау максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектлары, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектлары, Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының расланган территорияләрне планлаштыру схемалары проектларына кертелә торган үзгәрешләр, Россия Федерациясе субъектларының расланган территорияләрне планлаштыру схемалары проектларына кертелә торган үзгәрешләр;»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының территорияләрне планлаштыру схемалары проектлары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының расланган территорияләрне планлаштыру схемаларына кертелә торган үзгәрешләр, әгәр дә аларның территорияләрендә төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре булса;»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы җирлекләренең, шәһәр округларының генераль планнары проектлары, җирлекләрнең, шәһәр округларының расланган генераль планнарына кертелә торган үзгәрешләр, әгәр дә:»;

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемасы проектын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемасы проектын, муниципаль районның территорияләрне планлаштыру схемасы проектын килештерү вакыты территорияләрне планлаштыруның мәгълүмат системасында әлеге проектларны һәм аларны нигезләү буенча материалларны кереп карау мөмкинлеген тәэмин итү турында хәбәрнамә (алга таба – документ проектын кереп карау мөмкинлеген тәэмин итү турында хәбәрнамә) кергән көннән өч айдан да артып китә алмый, җирлекнең, шәһәр округының генераль планы проектын килештерү вакыты документ проектын кереп карау мөмкинлеген тәэмин итү турында хәбәрнамә кергән көннән ике айдан да артып китә алмый.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.1, 3.2 нче пунктлар өстәргә:

«3.1. Ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының расланган территорияләрне планлаштыру схемасына кертелә торган үзгәрешләрне, Россия Федерациясе субъектларының расланган территорияләрне планлаштыру схемасына кертелә торган үзгәрешләрне, муниципаль районның расланган территорияләрне

планлаштыру схемасына кертелә торган үзгәрешләрне, җирлекнең, шәһәр округының расланган генераль планына кертелә торган үзгәрешләрне (алга таба – расланган территорияләрне планлаштыру документлары) карап тикшерү вакыты түбәндәге очракларда документ проектын кереп карау мөмкинлеген тәэмин итү турында хәбәрнамә кергән көннән бер айдан да артып китә алмый:

а) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 26 статьясындагы 7 өлешендә каралган үзгәрешләр кертелгәндә;

б) ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының расланган территорияләрне планлаштыру схемасы, Россия Федерациясе субъектының расланган территорияләрне планлаштыру схемасы, муниципаль районның расланган территорияләрне планлаштыру схемасы, җирлекнең, шәһәр округының расланган генераль планы нигезендә урнаштырылуы күздә тотылган төбәк, җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү өлешендә үзгәрешләр кертелгәндә;

в) расланган территорияләрне планлаштыру документларын Россия Федерациясенең расланган территорияләрне планлаштыру документларына, ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының расланган территорияләрне планлаштыру документларына, Татарстан Республикасының расланган территорияләрне планлаштыру документларына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертелгәндә.

3.2. Бу Тәртипнең 3.1 нче пунктында каралмаган очракларда, расланган территорияләрне планлаштыру документларына кертелә торган үзгәрешләрне карап тикшерү вакыты документ проектын кереп карау мөмкинлеген тәэмин итү турында хәбәрнамә кергән көннән ике календарь айдан артып китә алмый.»;

6 нчы пунктта «3 эш көне» сүзләрен «бер эш көне» сүзләренә алыштырырга;

7 нче пунктта «3 эш көне» сүзләрен «өч эш көне» сүзләренә алыштырырга;

8 нче пунктта «әлеге хәбәрнамәне алган көннән 30 көн эчендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Килештерүче органнар һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемасы проектын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемасы проектын, Татарстан Республикасы муниципаль районының территорияләрне планлаштыру схемасы проектын карап тикшерә һәм документ проектын кереп карау мөмкинлеген тәэмин итү турында хәбәрнамә алган көннән 30 календарь көн эчендә бәяләмәләр әзерли, җирлекнең, шәһәр округының генераль планы проектын карап тикшерә һәм документ проектын кереп карау мөмкинлеген тәэмин итү турында хәбәрнамә алган көннән 20 календарь көн эчендә бәяләмәләр әзерли.»;

түбәндәге эчтәлекле 9.1, 9.2 нче пунктлар өстәргә:

«9.1. Бу Тәртипнең 3.1 нче пунктында каралган очракларда, килештерүче органнар һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының расланган территорияләрне планлаштыру схемаларына, Россия Федерациясе субъектларының расланган территорияләрне планлаштыру

схемаларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең расланган территорияләрне планлаштыру схемаларына, җирлекләрнең, шәһәр округларының расланган генераль планнарына кертелә торган үзгәрешләрне карап тикшерү вакыты документ проектын кереп карау мөмкинлеген тәэмин итү турында хәбәрнамә алган көннән җиде календарь көннән артып китә алмый.

9.2. Бу Тәртипнең 3.2 нче пунктында каралган очракларда, килештерүче органнар һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының расланган территорияләрне планлаштыру схемаларына, Россия Федерациясе субъектларының расланган территорияләрне планлаштыру схемаларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең расланган территорияләрне планлаштыру схемаларына, җирлекләрнең, шәһәр округларының расланган генераль планнарына кертелә торган үзгәрешләрне карап тикшерү вакыты документ проектын кереп карау мөмкинлеген тәэмин итү турында хәбәрнамә кергән көннән 20 календарь көннән артып китә алмый.»;

11 нче пунктта «21 көн» сүзләрен «биш календарь көн» сүзләренә алыштырырга, «9 нчы пунктында билгеләнгән вакыт» сүзләрен «9, 9.1, 9.2 нче пунктларында билгеләнгән вакытлар» сүзләренә алыштырырга;

13 нче пунктта «бу Тәртипнең 9 нчы пунктында билгеләнгән вакыт» сүзләрен «бу Тәртипнең 9, 9.1, 9.2 нче пунктларында билгеләнгән вакытлар» сүзләренә алыштырырга;

14 нче пунктта «7 эш көне» сүзләрен «биш эш көне» сүзләренә алыштырырга, «9 нчы пунктында билгеләнгән вакыт» сүзләрен «9, 9.1, 9.2 нче пунктларында билгеләнгән вакытлар» сүзләренә алыштырырга;

17 нче пунктта «3 эш көне» сүзләрен «ике эш көне» сүзләренә алыштырырга;

18 нче пунктта «21 көн» сүзләрен «биш календарь көн» сүзләренә алыштырырга;

19 нчы пунктта «5 эш көне» сүзләрен «бер эш көне» сүзләренә алыштырырга;

20 нче пунктта «5 эш көне» сүзләрен «биш эш көне» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин